# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның Татарстан Республикасы территориясендә яшәү кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында**

Бу Закон чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның Татарстан Республикасы территориясендә яшәү кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыгын билгели.

1 статья. Әлеге Законның гамәли чикләре

Әлеге Законда каралган хокук бозулар законнар нигезендә җинаять җаваплылыгына китермәсә, административ җаваплылык карала.

2 статья. Чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның билгеләнгән яшәү кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыгы

Чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга билгеләнгән яшәү кагыйдәләрен бозган, ягъни Россия Федерациясендә яшәү хокукы бирә торган документлары булмаган килеш яки ялган документлар белән яшәгән, теркәүнең мәгълүм тәртибен бозган, билгеләнгән яшәү вакыты чыкканнан соң да китми калган,шулай ук Россия Федерациясе территориясе аша транзит белән узу кагыйдәләрен үтәмәгән өчен -

хезмәт өчен түләүнең егерме биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

Шул ук гамәлләр административ җәза чаралары күрелгәннән

соң да, ел дәвамында кабатланса -

хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына, әгәр хокук бозучының шәхесен истә тотып, күрелгән чаралар җитәрлек түгел дип танылса, унбиш тәүлеккә кадәр административ кулга алу карала.

3 статья. Чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларның яшәү кагыйдәләрен бозган өчен урындагы затларның җаваплылыгы

Чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны кабул итүче яисә аларга хезмәт күрсәтүне тәэмин итүче дәүләт хакимияте һәм идарәсе, җирле үзидарә органнарының, юридик затларының да, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның Россия Федерациясендә яшәү һәм Россия Федерациясе территориясе аша транзит белән узу, аларны тиешле тәртиптә теркәү шартларын, алар өчен яшәүгә, күчеп китүгә һәм яшәү, күчеп китү урынын үзгәртүгә хокук бирүче документларны рәсмиләштерү шартларын үтәүгә бәйле эшләрне башкаручы урындагы кешеләренә хокук бозган өчен -

хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

Шул ук гамәлләр административ җәза чаралары күрелгәннән соң да ел дәвамында кабатланса -

хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

4 статья. Чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның яшәү кагыйдәләрен бозган гражданнарның җаваплылыгы

Чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны чакыручы һәм (яисә) кабул итүче һәм (яисә) аларга торак мәйданы бирүче гражданнарга, шул исәптән чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга билгеләнгән тәртиптә аларны вакытында теркәү һәм күчеп китүне тәэмин итү чаралары күрмәгән өчен -

хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф

салына.

Шул ук гамәлләр административ җәза чаралары күрелгәннән соң да ел дәвмында кабатланса -

хезмәт өчен түләүнең егермедән алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

5 статья. Административ куу

Билгеләнгән яшәү кагыйдәләрен тупас бозган чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар законнар нигезендә административ рәвештә Россия Федерациясеннән читкә куылалар.

Хокук бозучы административ куу чыгымнарын түли алмаган очракта, аны Россия Федерациясеннән читкә мәҗбүри куу һәм тикшереп тору чыгымнары Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының махсус счетыннан бүлеп бирелә.

6 статья. Штрафларның суммасын бүлү

Әлеге Законда каралган штрафлар суммасының 25 проценты - хокук бозу булган шәһәрләрнең, районнарның бюджетларына, 75 проценты Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының махсус счетына җибәрелә.

7 статья. Административ хокук бозу турында беркетмә

Бу Законда күрсәтелгән хокук бозу турындагы беркетмә административ хокук бозулар турындагы законнар нигезендә эчке эшләр органнарының махсус вәкаләт бирелгән урындагы затлары тарафыннан төзелә.

8 статья. Чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның яшәү кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турындагы эшләрне карау тәртибе

Бу Законда күрсәтелгән хокук бозулар турындагы эшләр административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә карала.

104



9 статья. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карауга вәкаләтле органнар

Әлеге Законның 2 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән хокук бозулар турындагы эшләрне район (шәһәр) судлары һәм эчке эшләр органнары (штраф салу өлешендә) карый.

Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешендә, 3,4 статьяларында күрсәтелгән хокук бозулар турындагы эшләрне эчке эшләр органнары карый.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1997 елның 12 феврале
N 1036